ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

02.11.2020 № 96

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукларын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Югары Ослан муниципаль районы Советының 2020нче елның 4нче июнендәге 58-670нче номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең генераль планын карау буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

2.2. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү вакыты - 2020нче елның 5нче ноябреннән 2020нче елның 7нче декабренә кадәр.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

3.2. Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуларның башлануы турында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында хәбәр итәргә.

3.3. 2020нче елның  5нче ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең генераль планы проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында текст формасында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Макыл авыл җирлегенең барлык торак пунктларында проектлар буенча экспозицияләр оештырырга.

Тәкъдимнәр, искәрмәләр кабул ителә:

1) Югары Ослан муниципаль районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ рәсми сайты аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 адресы буенча, яки Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетына: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Рус Макылы авылы, Пионерская урамы, 18 адресы буенча;

3) җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналында язылу юлы белән.

3.4. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль район Башлыгы урынбасары С. В. Осянин